### Список использованных источников и литературы

1. Ишеев М. Татарские князья и их княжества: сб. статей и материалов / под ред. М.Ишеева. – Н.Новгород: Медина, 2008.

2. Ишеев М. Татарские княжеские роды на Цне / М.Ишеев, М.Акчурин, А.Абдиев // Сборник материалов 6-й ежегодной научно-практической конференции «Фаизхановские чтения». – Н.Новгород, 2009 (в печати).

3. Гераклитов А.А. Арзамасская мордва по Писцовым и Переписным книгам XVII–XVIII вв. / А.А.Гераклитов // Ученые записки Саратовского гос. университета. – 1930. – Т.8. – Вып.2.

4. Временник Императорского Московского общества истории и древностей российских. – 1850. – Кн.5. – Ч.3.

5. Чтения в Императорском обществе истории и древностей российских. – 1898. – Кн. 2.

6. Документы и материалы по истории Мордовской АССР. – Т.1. – Саранск: МНИИЯЛИ, 1940.

7. Барбаро И. Путешествие в Тану // Барбаро и Контарини о России. – М.: Наука, 1971.

8. Арзамасские поместные акты (1578–1618 гг.) // Чтения в Императорском обществе истории и древностей российских / ред. С.Б.Веселовский. – 1916. – Кн.1 (256).

9. Документы Печатного приказа (1613–1615 гг.) / акад. С.Б.Веселовский. – М.: Наука, 1994.

10. Кириченко Л.А. Актовый материал Троице-Сергиева монастыря 1584–1641 гг. как источник по истории землевладения и хозяйства. – М., 2006.

11. Восстание И. Болотникова. Документы и материалы / сост. А.И.Копанев и А.Г.Маньков. – М., 1959.

12. Сенюткин С.Б. История татар Нижегородского Поволжья с последней трети XVI – до начала XX вв. (Историческая судьба мишарей Нижегородского края). – Н.Новгород: Изд-во ННГУ, 2001.

13. Алатырский уезд в XVII веке. Документы приказного делопроизводства / сост. Б.М.Пудалов, А.Чибис. http://www.opentextnn.ru/history/rushist/dorevigu/gubnn/prikaz/?id=878.

14. Труды Саратовской ученой архивной комиссии. – 1902. – Вып.22.

15. Дворянские роды Российской империи. – Т.3. Князья / под ред. С.В.Думина. – М.: Ликоминвест, 1996.

16. Чтения в Императорском обществе истории и древностей российских. – 1913. – Кн.4.

17. Древние акты, относящиеся к истории Вятского края. Прил. к 2-му т. сб. «Столетие Вятской губернии». – Вятка, 1881.

18. Антонов А.В. Акты служилых землевладельцев XV – начала XVII века. – Т.III / сост. А.В.Антонов. – М., 2002.

19. Орлов А.М. Нижегородские татары: этнические корни и исторические судьбы / А.М.Орлов. – http://mishare.narod.ru/books/Ethnic_roots/.

20. Известия общества археологии, истории и этнографии. – 1893. – Т.XI. – Вып.3.

21. Информационная полнотекстовая система «Боярские списки XVIII века» / А.В.Захаров. – http://zaharov.csu.ru/.

22. Материалы исторические и юридические района бывшего Приказа Казанского дворца. – Т.1. Архив князя В.И.Баюшева / проф. Н.П.Загоскин. – Казань, 1882.

23. Крестьянская война под предводительством Степана Разина: сборник документов. – Т.II. – Ч.1. – М., 1954.

24. Материалы по истории Башкирской АССР. – Т.IV. – Ч.II. – М., 1956.

25. Ислаев Ф. Татары в Екатерининской уложенной комиссии 1767–1768 гг. / Ф.Ислаев // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2003. – № 3/4.

26. Документы и материалы по истории Мордовской АССР. – Т.III. – Ч.II . – Саранск, 1953.

27. Документы и материалы по истории Мордовской АССР. – Т.III. – Ч.I . – Саранск, 1939.

28. Десятни Пензенского края (1669–1696) / под ред. А.Барсукова // Русская историческая библиотека. – Т.17. – СПб., 1898.

29. Гераклитов А.А. Материалы по истории мордвы. – М.: Соцэкгиз, 1931.

30. Христофоров И. Исторические акты, относящиеся до обращения в христианство, при царе Федоре Алексеевиче, князей и мурз татарских а также мордвы, черемис и других инородцев.

*М.И. Әхмәтҗанов*

## Кара бәк шәҗәрәсенең Мөрсәйет тармагы

Кара бәк нәсел шәҗәрәсенең Мөрсәйет тармагы кулъязмасы 2010 елда гына табылды. Бу тармакның нәсел шәҗәрәсе чылбыры фәндә якынча гына билгеле. Әйтик, Мөрсәйет бине Ильяс бине Мөхәммәт бине Кара би шәҗәрәсе, беренчеләрдән булып, архив материаллары нигезендә Вятка шәһәренең крайны өйрәнүче П.М.Сорокин тарафыннан өйрәнелә башлый [1, с.45–61].

Соңгы елларда шәҗәрәнең бу тармагын тарих фәннәре докторы Д.М.Исхаков шулай ук архив материаллары нигезендә өйрәнгән [2, с.60–67].

Кара бәк нәселенең Мөрсәйет тармагы шәҗәрәсе турында аерым хәбәрләр булса да, аның матбугатка чыккан версиясе әлегә кадәр тулы килеш бирелгәне юк иде.

Күптән түгел Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсендә табылган материаллардан күренгәнчә, 1792 елда Вятка өяз судына Ильяс авылында (хәзерге Киров өлкәсе, Слободской районындагы авыл) яшәүче кенәз Мөрсәйет нәселеннән булган кешеләрнең үзләренә кенәзлек өстенлекләрен кайтару өчен тәгаенләнгән үтенечләренә кенәз Мөрсәйетнең нәсел шәҗәрәсе дә кушып бирелә. Соңыннан бу шәҗәрә 1936 елда Слободской районында Кебешел Вәли исемле кеше кулына, аннан Нократ авылы кешесе Абашев Садыр Закир улы кулына эләгә һәм 1968 елның 10 гыйнварында ул аны Галимҗан Ибраһимов исемендәге Институтка китереп тапшыра. Хәзер шәҗәрә кулъязмасы мирасханәнең шәҗәрәләр коллекциясендә саклана [3].

Шәҗәрә кечерәк кәгазь битләреннән ябыштырып ясалган зур табаклы биткә, ә текст трапеция формасындагы кәгазьгә коңгырт кара белән язылган. Бу трапециянең өске өлеше киңлеге – 45 см, түбәнге өлеше киңлеге – 193 см. Кәгазьнең, ягъни битнең, буй үлчәме – 104 см.

Кәгазь, берничә кисәккә бөкләнеп, картон папка эченә салынган. Бөкләнгән урыннарда тишекләр барлыкка килеп, текстның беркадәр бозылуына китергән.

Текст урыс телендәге борынгы чыганакларга таянып язылган. Күчерүчеләр борынгы татар исемнәрендә ялгышлар да җибәргәннәр, ул ялгышларның шактый өлешен төзәтеп укып була.

Шәҗәрәдә кеше исемнәре түгәрәкләр эченә борынгы урыс хәрефләре белән һәм орфография таләпләренә туры китереп язылганнар.

Бу текст шуны ачыклый: Кара бәк нәселе, үзләренең борынгы фамилияләрен саклап калып, төрле районнарга таралып утырган. Күчеп киткән нәсел исемнәре, яңа табылган текстта сакланып, аларның Кара бәк нәселенә ялгану чылбырын күрсәтә. Әгерҗе төбәгендәге Янчурин, Арсланов, Байкеев һ.б. фамилияләрнең Кара бәккә барып тоташуын да әлеге текст ярдәмендә генә белә алдык.

Шәҗәрәдә төп баба итеп күрсәтелгән Мөрсәйет кенәзгә 1548 елда Иван Грозный җир алу өчен ярлыкаш грамота биргән. Ул вакытта Мөрсәйетнең Муса, Мортаза, Агыш, Дөнәш, Нурислам, Шәйислам исемле алты улы була. Дөнәш һәм Шәйисламнан борынгы Дуняшев, Зянчурин (Янчурин), Арсланов, Касыймов фамилияләре барлыкка килгән.

Шәҗәрә, Мөрсәйетне дә кертеп, тугыз буын тәшкил итә һәм Мөрсәйет (Мирсәйет) Ильяс углын XV гасырның соңгы чирегендә туган кеше дип тәгаенләп була. Ихтимал, киләчәктә тарихчылар, Кара бәк нәселенә бирелгән ярлыкаш грамоталарны туплап, бу нәселнең аерым бер вакыт эчендә ирешкән казанышларын да ачыклый алырлар, дип өмет итәбез.

**Родословная (Каринского князя Мурсаитова)**
**(XV–XVI в.)**

| | | |
|---|---|---|
| | *I поколение* | |
| 1. | Мурсаит, умер | |
| | *II поколение* | |
| 2. | Князь Шаислям | 1 |
| 3. | Князь Нурыслям, бездетный | 1 |
| 4. | Князь Дуняш | 1 |
| 5. | Князь Агиш, бездетный | 1 |
| 6. | Князь Муртаза, бездетный | 1 |
| 7. | Князь Мусса, бездетный<br>1548–42–45 лет | 1 |
| | *III поколение* | |
| 8. | Буран | 2 |
| 9. | Бичюра, род его выбыл в Оренбург | 4 |
| 10. | Зянчура | 4 |
| 11. | Тышле | 4 |
| | *IV поколение* | |
| 12. | Богдан | 8 |
| 13. | Зямбахта, роду не осталось | 10 |
| 14. | Байкуат | 10 |
| 15. | Кадыш | 10 |
| 16. | Алыш | 10 |

| | | |
|---|---|---|
| | *V поколение* | |
| 17. | Баиш | 11 |
| 18. | Арслан | 12 |
| 19. | Кузябай | 14 |
| 20. | Динабай, бездетный | 14 |
| 21. | Багыш | 15 |
| 22. | Мами | 15 |
| 23. | Асеко | 16 |
| 24. | Есей | 17 |
| 25. | Ешмерьзя | 17 |
| | *VI поколение* | |
| 26. | Уразан | 18 |
| 27. | Мустафа | 18 |
| 28. | Муртаза | 18 |
| 29. | Сабай | 18 |
| 30. | Маметкул | 19 |
| 31. | Беткул | 19 |
| 32. | Мамедберди | 19 |
| 33. | Кадыр | 19 |
| 34. | Маметгали | 21 |
| 35. | Баим... | 22 |
| 36. | Сулейман | 22 |
| 37. | Араслан | 23 |
| 38. | Шагум | 24 |
| 39. | Маметкум | 24 |
| 40. | Апас | 24 |
| 41. | Разеп | 24 |
| 42. | Акйас | 25 |
| 43. | Бекмерзя | 25 |
| 44. | Хузой | 25 |
| | *VII поколение* | |
| 45. | Ханса | 26 |
| 46. | Баглан | 26 |
| 47. | Бектемир | 27 |
| 48. | Саитхузя | 27 |
| 49. | Искендерь | 27 |
| 50. | Хадияр, Тухай переселились | 27 |
| 51. | в округ | 27 |
| 52. | Абдразай | 28 |
| 53. | Аскей | 29 |
| 54. | Усман | 29 |
| 55. | Сафар | 30 |
| 56. | Илька | 30 |
| 57. | Бектемир | 31 |
| 58. | Рамазан | 32 |
| 59. | Атабай | 32 |
| 60. | Абдулла | 32 |
| 61. | Мустафа | 32 |
| 62. | Искак | 32 |
| 63. | Муксин, холость | 32 |
| 64. | Аймурза | 33 |
| 65. | Сулейман | 34 |
| 66. | Мавлеша | 35 |
| 67. | Кули | 36 |
| 68. | Заит | 37 |
| 69. | Ишкинъ | 37 |
| 70. | Есеней | 38 |
| 71. | Кулыш | 38 |
| 72. | Бегеней | 39 |
| 73. | Бектемир | 39 |
| 74. | Герей | 40 |
| 75. | Эркен | 40 |
| 76. | Мускес | 40 |

| | | |
|---|---|---|
| 77. | Смагиль | 40 |
| 78. | Мамык | 41 |
| 79. | Думанай | 42 |
| 80. | Рысь | 43 |
| 81. | Смагиль | 44 |
| 82. | Аймурза | 44 |
| | *VIII поколение* | |
| 83. | Ильяс | 45 |
| 84. | Бизян (Биҗан – М.Ә.) | 46 |
| 85. | Васыйл | 47 |
| 86. | Атабай | 47 |
| 87. | Юнус | 47 |
| 88. | Мамекуш | 48 |
| 89. | Ишметь | 49 |
| 90. | Агатлан | 49 |
| 91. | Иброш | 52 |
| 92. | Джагфар | 53 |
| 93. | Гами | 53 |
| 94. | Усаин | 54 |
| 95. | Уразай | 54 |
| 96. | Сагить | 54 |
| 97. | Амыръ (умер в рекруты) | 55 |
| 98. | Ибрай | 55 |
| 99. | Гуссаин | 56 |
| 100. | Мустафа | 56 |
| 101. | Смагиль | 56 |
| 102. | Абдунабий | 57 |
| 103. | Рахматулла (умер в рекруты) | 57 |
| 104. | Муртаза | 57 |
| 105. | Ишали | 57 |
| 106. | Батарей | 58 |
| 107. | Саит | 58 |
| 108. | Сулейман умер… | 58 |
| 109. | Резепь | 59 |
| 110. | Салим | 59 |
| 111. | Халил | 60 |
| 112. | Габид | 60 |
| 113. | Газинур | 60 |
| 114. | Мусалим | 61 |
| 115. | Ярадым | 61 |
| 116. | Мухаммедрагим | 61 |
| 117. | Манасып | 61 |
| 118. | Абдулмазит | 61 |
| 119. | Яхъя | 62 |
| 120. | Абдурашит | 62 |
| 121. | Смагиль | 64 |
| 122. | Назырь | 64 |
| 123. | Васимь | 65 |
| 124. | Абри | 65 |
| 125. | Усман | 65 |
| 126. | Шарип | 66 |
| 127. | Юсуп | 67 |
| 128. | Надыр, умер в рекруты | 67 |
| 129. | Самей | 68 |
| 130. | Шабдгунъ | 68 |
| 131. | Сагид | 69 |
| 132. | Риза | 69 |
| 133. | Мустай | 70 |
| 134. | Ходар | 71 |
| 135. | Мамедберди | 72 |
| 136. | Иштерек | 73 |
| 137. | Юсуп | 74 |
| 138. | Мусавам | 75 |

| | | |
|---|---|---|
| 139. | Муртаза | 76 |
| 140. | Салих | 76 |
| 141. | Хамид, умер в рекруты | 76 |
| 142. | Сагид | 76 |
| 143. | Сабаин | 77 |
| 144. | Искеби | 77 |
| 145. | Ашабай | 78 |
| 146. | Мусса | 78 |
| 147. | Ишмерза | 79 |
| 148. | Бикмерза | 79 |
| 149. | Итай | 80 |
| 150. | Мирас | 81 |
| 151. | Ермак | 82 |
| 152. | Мустафа | 82 |
| 153. | Хабиб | 82 |
| 154. | Абдулла | 82 |
| 155. | Абдрахман | 82 |
| 156. | Сулейман | 82 |
| | *IX поколение* | |
| 157. | Апас | 83 |
| 158. | Усмон | 84 |
| 159. | Бектемир | 84 |
| 160. | Исуп | 84 |
| 161. | Мусалим | 84 |
| 162. | Хула | 85 |
| 163. | Рашид | 85 |
| 164. | Ахмай | 86 |
| 165. | Мусса | 86 |
| 166. | Гайса | 86 |
| 167. | Касым | 86 |
| 168. | Мамет | 87 |
| 169. | Масси | 87 |
| 170. | Мустафа | 87 |
| 171. | Абди | 88 |
| 172. | Апас | 89 |
| 173. | Агит | 90 |
| 174. | Есянь | 91 |
| 175. | Гумар | 92 |
| 176. | Амин, умер в рекруты | 92 |
| 177. | Муслим | 92 |
| 178. | Яхъя | 93 |
| 178. | Абдулла | 93 |
| 180. | Субай | 93 |
| 181. | Ишали | 94 |
| 182. | Ешмурза | 95 |
| 183. | Ермак | 95 |
| 184. | Файзулла | 96 |
| 185. | Якуп | 96 |
| 186. | Абдурахим | 96 |
| 187. | Гайса | 96 |
| 188. | Хамит | 97 |
| 189. | Тагирь | 98 |
| 190. | Маднай | 98 |
| 191. | Мустафа | 98 |
| 192. | ? | 99 |
| 193. | Амин | 102 |
| 194. | Гали | 102 |
| 195. | Мавли | 109 |
| 196. | Мусавим | 109 |
| 197. | ? | 109 |
| 198. | ? | 123 |
| 199. | ? | 124 |
| 200. | Габдулла | 124 |

| | | |
|---|---|---|
| 201. | Ибрагим, в рекруты | 125 |
| 202. | Халил | 125 |
| 203. | ? | 125 |
| 204. | Гумар | 125 |
| 205. | Мусса | 126 |

**Чыганаклар һәм әдәбият исемлеге**

1. Сорокин П.М. Арские князья в Карнне // Календарь и Памятная книжка Вятской губернии на 1895 г. – Вятка, 1894.

2. Исхаков Д.М. Патронимия у чепецких татар // Новое в этнографических исследованиях татарского народа. – Казань, 1978.

3. Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Кульъязмалар, фәнни һәм архив бүлеге мирасханәсе. – 99 кол. – 1 тас. – сак. бер.

***Н.Г. Гариф***

## Казан ханлыгы чоры эпиграфик һәйкәлләрендә социаль титуллар чагылышы

Безнең тарафтан Казан ханлыгы чорына караган 297 язма кабер ташы барланды. Ташларның 90нан артыгында (80–100%ка) ташның куелу вакыты, таш куелган шәхеснең исеме, дәрәҗәсе, ташны куючы һәм башка төр мәгълүмат сакланып калган. Кызганыч: ташларның куелу вакыты һәм җирләнгән кешеләрнең исем-атамасы, дәрәҗәсе язылган урын ташның аскы, иң начар сакланышлы җиренә туры килгән. Шуңа да карамастан, бүгенге көндә әлеге ташларның 69нда шәхесләрнең дәрәҗәсен ачыклау мөмкинлеге сакланган (таблица).

Язмалардан күренгәнчә, әлеге эпиграфик һәйкәлләр күп очракта югары катлау әһелләренә: дәүләт хезмәтендәге җитәкчеләргә, гаскәр башлыкларына, абруйлы руханиларга, эре җир биләүчеләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына куелган.

Дәүләт хезмәтендә булган югары катлау кешеләрен Казанда яшәсәләр дә, хан ярлыгы белән беркетелгән, хан тарафыннан бүләк ителгән җир биләмәләре, авыллары булган. Җәй көне еш кына шул авылларында, үз җирләрендә ял иткәннәр, монда аларның утарлары, җәйге йортлары булган, хезмәтчеләре торган. Вафат булган очракта, аларны күбесенчә үз утарларында җирләгәннәр. Шулай итеп, еллар узу белән, гаиләнең бакыйга күчкән шактый әгъзасы бер урынга тупланып, гаилә каберлекләре дә барлыкка килгән. Бер үк урында бер үк типтагы кабер ташларының куелуы шул хакта сөйли. Шундый ук ташлар җирле идарәчеләрнең югары катлау кешеләренә дә куелган. Кабер ташлы зиратлар күп очракта зур мәйдан биләми. Шул сәбәпле, гади игенчеләр, терлекчеләр зиратларның аерым җирдә урнашулары турында да фикер йөртергә мөмкин. Бай, мәһабәт каберташлар янында гади, кечкенә ташлар очрамый. Әлеге фикер таш язмаларга анализ ясаганнан соң да ныгый.

Эпиграфик ташлардагы язмаларның эчтәлеген өйрәнү җирле феодалларның титул-дәрәҗәләре, исемнәре һәм яшәгән елларын билгеләү мөмкинлеген тудыра.

Ташъязмаларда, дәрәҗә буларак (кеше исеме буларак искә алынуы да ихтимал), Бөек солтан – 4 тапкыр, Солтан – 7, Әмир – 3, Карача – 1, Би-Бәк-Бәй – 1), Бикә – 7, Бикәч – 7, Морза 3 тапкыр искә алынган. Ташъязмаларда дини һәм хәрби дәрәҗәләр дә чагылыш таба. Мәсәлән: Сәед (3), Чура (4), Хафиз (4), Дәрвиш (2), Шәех (7), Хаҗи (5), Мәүлә (2), Абыз, ага (3), Суфый 2 тапкыр очрый. Язмаларда шулай ук Остаз, Чиләби (Мөдәррис), Әфәнде, Бакшы (Хисапчы), Ябынчы (Сакчы) атамалары да бар.

Ташлардагы мәгълүмат буенча ханлыктагы иерархик система, аерым төбәкләрнең үзенчәлекләре дә күзаллана. Мәсәлән, Олы Солтан, дәрәҗә буларак, бары Арча, Әтнә төбәгендәге кабер ташларына гына хас. Казанда табылган ташларда бәк атамасы өстенлек итә. Ә Казаннан ерагайган саен, мәсәлән, тау ягында, Мишә төбәгендә кечерәк дәрәҗәдәге атамалар күбрәк урын алган. Морза атамасы уелган өч ташның икесе Борынгы Чаллы төбәгендә сакланып калган (1 рәсем).

Кабер ташларындагы язуларның 20 процентында таш куелган шәхесләрнең «кяфер кулындин», «Мәскәү», яисә «урыс явы килгәндә» шәһит киткәнлекләре билгеләнгән.